КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 сентябрь г.Казань № 1096

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре;

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 14 сентябрь, 994 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 8 июль, 803 нче;

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 сентябрь, 1096 нчы
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив чыгымнар, бер елга бер берәмлеккә сум | Бер елга хезмәт күрсәтүләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыруга һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләт-ләрен үтәүгә бәйле архив белешмәләре, архив кү-чермәләре, архив өземтә-ләре, мәгълүмат хатлары бирү | 2 219,33 | 16 000 | үтәлгән рәсми сораулар саны, берәмлек |
| 2. | Архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм аларга белешмә-эзләнү чараларыннан файдалана алуны тәэмин итү | 1 664,50 | 12 000 | уку залында булу саны, берәмлек |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 7 сентябрь, 1096 нчы
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш башкару исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 22 193 338 |
| 2. | Архив документларының сакланышын һәм исәбен тәэмин итү | 45 496 343 |
| 3. | Архив документларын тасвирлау, белешмә-эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә-мәгълүмат басмалары әзерләү | 11 096 669 |
| 4. | Дәүләт серен, архив документларындагы закон белән саклана торган башка серләрне тәшкил итүче белешмәләрне саклау һәм аларны билгеләнгән тәртиптә таратуны оештыру | 4 438 732 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәне документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация һәм методика ярдәме | 6 658 001 |
| 6. | Архив документларының белешмә һәм эзләү чараларыннан «ерактан торып» файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 7 767 668 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмати чараларны, публикатор һәм күргәзмә проектларны гамәлгә ашыру | 11 096 669 |

___________________________